БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
15 марта 2021 г.

**КАРАР**
№ 46

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибен раслау турында**

«Җир өчен аренда түләве турында» 1995 елның 9 февралендәге 74 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, һәм эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү өчен тигез шартлар тудыру максатларында Балтач муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Балтач муниципаль районы Советының социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р. Р. Нотфуллин

Балтач муниципаль районы Советының
2021 елның 15 март
46 номерлы карарына
1 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ МИЛКЕНДӘГЕ ҖИР КИШӘРЛЕКЛӘРЕ ӨЧЕН АРЕНДА ТҮЛӘВЕ КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ ТӘРТИБЕ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган, юридик һәм физик затларга, шәхси эшкуарларга арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгели.

1.2. Әлеге тәртип җир кишәрлекләрен сатулар үткәрмичә арендага бирү очракларына кагыла.

1.3. Бина, корылмаларның бер өлешен арендага тапшырганда, бина, корылма биләгән җир һәм әлеге корылмаларның арендага алына торган мәйданы буенча туры китереп, аларны карап тоту өчен кирәкле җир өчен аренда түләве алына. Җир өчен аренда түләве бинаны яки корылманы файдаланган өчен аренда түләвенә кертелә.

1.4. Гамәлдәге законнарда билгеләнгән җир салымын түләү буенча ташламалар, җирле үзидарә органнарының норматив актларында билгеләнгән өстәмә ташламалар җирне арендага алучыларга - юридик затларга һәм гражданнарга кагыла.

1.5. Җир кишәрлеге, җир өчен аренда түләве буенча ташламалары булган арендага алучы тарафыннан ташламасы булмаган затка субарендага бирелгән очракта, субарендага алучы гомуми нигезләрдә җир өчен аренда түләве кертергә тиеш.

1.6. Җир кишәрлеге, җир өчен аренда түләве буенча ташламалары булмаган арендага алучы тарафыннан ташламасы булган затка субарендага биргән очракта, арендага алучы гомуми нигезләрдә җир өчен аренда түләве кертә.

1.7. Аренда түләве арендага, җир кишәрлеген арендага биргән айдан соң килгән айдан башлап, шул исәптән төзелеш чорына да исәпләнә һәм төзелгән шартнамәдә күрсәтелгән банк реквизитларына арендага алучы тарафыннан җир

кишәрлеген арендага биргән айдан соң килгән айның 5 числосыннан да соңга калмыйча ай саен кертелә.

1.8. Билгеләнгән вакытка түләмәгән очракта, арендага алучы түләү вакыты узган һәр көн өчен түләү вакыты узган һәр көн өчен аренда түләүләре суммасының 0,1% күләмендә пеня түли.

## 2. ҖИР ӨЧЕН АРЕНДА ТҮЛӘВЕ КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ

2.1. Җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен еллык аренда түләве күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

А = Кад.с*Нс* Кф,

биредә:

А - җир кишәрлеге өчен еллык аренда түләве күләме;

Кад.с. - җир кишәрлегенең кадастр бәясе;

Нс-җир салымы ставкасы;

Кф - әлеге Нигезләмәнең кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән файдалану төрен исәпкә ала торган җир салымы ставкасына төзәтү коэффициенты.

2.2. «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октяберендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - Закон) 3 статьясының 2 пункты нигезендә, Законда каралган тәртиптә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яңадан рәсмиләштергәндә, җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен еллык аренда түләве күләме Нигезләмәнең 2.1 пункты нигезендә түбәндәге чикләрдә (арткан очракта - тигез күләмдә) исәпләп чыгарыла:

арендалана торган җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең ике проценты;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән арендага алына торган җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең уннан өч проценты;

әйләнештән алынган яисә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең бер ярым проценты.

2.3. Объектлар төзү барышында җир кишәрлегеннән файдаланган өчен аренда түләве күләме, рөхсәт ителгән файдалану төрен һәм билгеләнгән җир кишәрлегеннән файдалануның тиешле төре буенча төзәтү коэффициентын исәпкә алып билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
муниципаль милкендәге
җир кишәрлекләре өчен
аренда түләве күләмен билгеләү
тәртибенә кушымта

ҖИР КИШӘРЛЕГЕННӘН ФАЙДАЛАНУ ТӨРЕН ИСӘПКӘ АЛА ТОРГАН ТӨЗӘТҮ КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

| Җир кишәрлегеннән файдалану төре | Коэффициент |
|---|---|
| Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | 1,0 |
| Торак, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача төзелеше өчен | 1,0 |
| Җитештерү өлкәсе объектлары өчен | 1,0 |
| Электростанцияләр, аларга хезмәт күрсәтүче корылмалар һәм объектлар урнаштыру өчен билгеләнгән объектлар өчен | 1,0 |
| Портларны, су, тимер юл вокзалларын, юл вокзалларын, аэровокзалларны урнаштыру өчен билгеләнгән объектлар өчен | 1,0 |
| Файдалы казылмалар чыгару, тимер юллар, ясалма эчке су юллары, причаллар, пристаньнар, тимер юл һәм автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосалар, су юллары, торбаүткәргечләр, кабель, радиорелей һәм һава элемтә линияләре, радиофикация линияләре, һава электр тапшыру линияләре, җир өсте һәм җир асты биналарын, төзелмәләрне, корылмаларны эксплуатацияләү, төзү, реконструкцияләү, ремонтлау, үстерү, транспорт, энергетика һәм элемтә урнаштыру өчен кирәкле конструктив элементларны һәм корылмаларны урнаштыру өчен; | 1,0 |

| | |
|---|---|
| иярчен элемтә җир өсте корылмаларын һәм инфраструктурасын, космик эшчәнлек объектларын урнаштыру өчен | |
| Склад объектлары өчен | 1,0 |
| Административ биналар, бүлмәләр һәм офислар өчен | 2,0 |
| Күпләп сату объектлары өчен | 4,0 |
| Җәмәгать туклануы объектлары өчен | 4,0 |
| Ваклап сату объектлары (кибетләр, сәүдә мәйданы белән павильоннар, ваклап сату киосклары), базар объектлары, даруханәләр өчен | 10,0 |
| Кунакханә өчен | 5,0 |
| Банк, иминият, биржа эшчәнлеге объектлары (шул исәптән түләү терминаллары) өчен | 10,0 |
| Реклама объектлары (нигезләрдә урнашкан реклама щиты һәм стендлар) өчен | 75,0 |
| Гаражлар өчен | 1,0 |
| Автомототранспортның ачык стоянкалары өчен | 3,0 |
| Автосервис объектлары һәм автозаправка станцияләре өчен | 4,5 |
| Автомототранспортның ябык күп катлы һәм җир асты машина кую урыны өчен | 0,5 - 2013 елның 1 июленә кадәр,<br>1,0 - 2013 елның 1 июленнән кадәр |
| Төзелеш чорына күпкатлы автотранспорт кую урыннары өчен | 0,1 - 2013 елның 1 июленә кадәр<br>1,0 - 2013 елның 1 |

| | |
|---|---|
| | июленнән кадәр |
| Махсус машина кую урыннары (токтарланган транспорт чаралары кую урыннары) өчен | 0,1 |
| Чистарту корылмалары объектлары өчен | 0,1 |
| «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законын гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган торакны һәм объектларны төзү өчен | 0,1 |
| Гражданнар авиациясе объектлары өчен | 0,1 |
| Спорт объектлары һәм корылмалары өчен | 0,17 |
| Рекреация һәм дәвалау-сәламәтләндерү объектлары өчен | 1,0 |
| Әйләнештәге су объектлары өчен | 1,0 |
| Скверлар, парклар булган объектлар өчен | 1,0 |
| Башка объектлар өчен | 2,0 |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә дәваланучы гражданнарга, озата баручы затларга вакытлыча түләүсез яшәү өчен билгеләнгән объектлар өчен | 0,1 |
| Медицина, социаль, психологик, юридик ярдәм күрсәтү өчен билгеләнгән хәйрия фондлары бины, төзелешләре һәм корылмалары (шул исәптән төзелеш чорына) өчен | 0,01 |
| Гидротехник корылмалар (су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау өчен, суларның зарарлы йогынтысын, шул исәптән сыек хәлдәге калдыклар белән пычранган, | 0,1 |

| | |
|---|---|
| плотиналарны, су ташлау, суүткәргеч һәм су чыгару корылмаларын да кертеп, булдырмау өчен билгеләнгән, су мохите йогынтысына дучар булган корылмалар) өчен;<br><br>насос станцияләре;<br><br>суднолар йөри торган шлюзлар;<br><br>судно күтәргечләр;<br><br>су басудан, сусаклагычларның ярларының, елга үзәннәренең ярларының һәм төбенең җимерелүеннән саклау өчен билгеләнгән корылмалар;<br><br>киртәләү корылмалары;<br><br>дамбалар, ярларны ныгыту корылмалары, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктурасы объектлары белән;<br><br>суднолар туктау өчен эшләнгән корылмалар (пирслар);<br><br>аларны булдыру, төзү, эксплуатацияләү, реконструкцияләү, модернизацияләү «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән шартнамәләр, килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла торган су белән тәэмин итү техник системалары корылмалары | |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 3 пунктчасы нигезендә бирелгән һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 25 пунктчасы нигезендә яисә «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре белән чиктәш чиге булган җир кишәрлекләрендә барлыкка килгән объектлар өчен | 0,1 |
| Гидротехник корылмалар (су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау өчен, суларның зарарлы йогынтысын, шул исәптән сыек хәлдәге калдыклар белән пычранган, плотиналарны, су ташлау, суүткәргеч һәм су чыгару корылмаларын да кертеп, булдырмау өчен билгеләнгән, су мохите йогынтысына дучар булган корылмалар) өчен; | 0,1 |

| | |
|---|---|
| насос станцияләре;<br>суднолар йөри торган шлюзлар;<br>судно күтәргечләр;<br>су басудан, сусаклагычларның ярларының, елга үзәннәренең ярларының һәм төбенең җимерелүеннән саклау өчен билгеләнгән корылмалар;<br>киртәләү корылмалары;<br>дамбалар, ярларны ныгыту корылмалары, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктурасы объектлары белән;<br>суднолар туктау өчен эшләнгән корылмалар (пирслар);<br>Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 25 пунктчасы нигезендә төзелгән арендалау шартнамәләре нигезендә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң үз акчалары һәм (яки) заем акчалары исәбеннән төзелә торган су белән тәэмин итү техник системалары корылмалары; | |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 3 пунктчасы нигезендә бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан сәламәтлек саклау объектлары өчен | 0,5<br>(җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзегәннән соң 5 ел вакытка) |